КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘДӘНИ МИРАС
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.05.2026 295-П

Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын, шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында

«Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законның 59 статьясындагы 7 өлеше, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тарихи җирлек территориясе чикләрен билгеләүгә карата таләпләрне раслау турында» 2013 елның 28 ноябрендәге 1095 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ (республика) әһәмияттәге тарихи җирлекләре исемлеген раслау турында» 2015 елның 26 мартындагы 188 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләрен расларга.
2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеген саклау предметын расларга.
3. Әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр расларга.
4. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (ФГИС ТП) Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә расланган территория чикләре, саклау предметы һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2026 елның
25 маендагы 295-П
номерлы боерыгына
1 нче кушымта

## Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләре

1 бүлек

| Объект турында белешмәләр | | |
|---|---|---|
| т/с | Объектка характеристика | Характеристикалар тасвирламасы |
| 1 | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Буа шәһәре |
| 2 | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләүдә хата зурлыгы (P +/- Дельта P) | 1 772 268,56301 кв.м +/- 0,1 кв.м |
| 3 | Объектның башка характеристикалары: периметры | 5 555,389265 м |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында белешмәләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координаталар системасы: МСК-16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында белешмәләр | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координаталар, м | | Характерлы ноктаның координаталарын билгеләү ысулы | Характерлы нокта торышының уртача квадрат хатасы (Mt), м | Урында ноктаны билгеләү тасвирламасы (булган очракта) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | 384972.78 | 1252032.15 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 2 | 384832.60 | 1252353.74 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 3 | 384969.99 | 1252412.01 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 4 | 384859.22 | 1252660.33 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 5 | 384670.21 | 1253064.08 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 6 | 384635.98 | 1253049.79 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 7 | 384492.79 | 1253383.73 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 8 | 384371.41 | 1253314.08 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 9 | 384256.77 | 1253242.88 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 10 | 384209.47 | 1253223.85 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 11 | 384170.11 | 1253224.38 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 12 | 384154.80 | 1253226.72 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 13 | 384131.00 | 1253225.28 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 14 | 384099.92 | 1253219.16 | Картометрик | 0.0007 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | 383957.86 | 1253160.41 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 16 | 383941.14 | 1253156.91 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 17 | 383812.03 | 1253103.83 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 18 | 383785.82 | 1253155.15 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 19 | 383722.21 | 1253098.56 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 20 | 383623.45 | 1253002.32 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 21 | 383532.84 | 1252873.97 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 22 | 383470.91 | 1252692.07 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 23 | 383475.66 | 1252592.36 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 24 | 383495.41 | 1252440.18 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 25 | 383528.57 | 1252252.86 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 26 | 383540.69 | 1252220.73 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 27 | 383598.18 | 1252120.15 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 28 | 383600.87 | 1251963.01 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 29 | 383721.17 | 1251964.79 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 30 | 383747.73 | 1251741.67 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 31 | 383941.26 | 1251800.54 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 32 | 384055.99 | 1251842.12 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 33 | 384155.29 | 1251635.80 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 34 | 384284.72 | 1251703.23 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 35 | 384566.02 | 1251840.73 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 36 | 384570.05 | 1251848.61 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 37 | 384669.34 | 1251903.19 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 38 | 384756.60 | 1251948.76 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 39 | 384843.96 | 1251985.87 | Картометрик | 0.0007 | - |
| 1 | 384972.78 | 1252032.15 | Картометрик | 0.0007 | - |

3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында белешмәләр

| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координаталар, м | | Характерлы ноктаның координаталарын билгеләү ысулы | Торышының уртача квадрат хатасы | Урындагы ноктаны билгеләү тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | характерлы нокта (Mt), м | (булган очракта) |
| - | - | - | - | - | - |


3 бүлек
Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләре урнашу урынының текстлы тасвирламасы

| Чикне узу | | Чикне узу |
|---|---|---|
| ноктасыннан | ноктасыннан | |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 2 | 1 ноктасыннан көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба чик Кызыл Армия урамы һәм 16:14:990140 кадастр кварталы территориясе буенча 2 ноктасына кадәр уза. |
| 2 | 3 | 2 ноктасыннан төньяк-төньяк-көнчыгышка таба чик Ефремов урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990140 кадастр кварталы чиге буйлап 3 ноктасына кадәр уза |
| 3 | 5 | 3 ноктасыннан көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба чик Төньяк Коммуна урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990139, 16:14:990138 кадастр кварталлары чиге буйлап 5 ноктасына кадәр уза |
| 5 | 6 | 5 ноктасыннан көньяк-көньяк-көнбатышка таба чик Жорес урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990138 кадастр кварталы чиге буйлап 6 ноктасына кадәр уза |
| 6 | 7 | 6 ноктасыннан көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба чик Төньяк Коммуна урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990137 кадастр кварталы чиге буйлап 7 ноктасына кадәр уза |
| 7 | 10 | 7 ноктасыннан көньяк-көньяк-көнбатышка таба чик Яр буе урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990137, 16:14:990146 кадастр кварталлары чиге буйлап 10 ноктасына кадәр уза |
| 10 | 13 | 10 ноктасыннан көньяк-көньяк-көнчыгышка таба чик Яр буе урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990146 кадастр кварталы чиге буйлап 13 ноктасына кадәр уза |
| 13 | 17 | 13 ноктасыннан көньяк-көньяк-көнбатышка таба чик Яр буе урамының үзәк сызыгы һәм 16:14:990146, 16:14:990147 кадастр кварталлары чиге буйлап 17 ноктасына кадәр уза |
| 17 | 18 | 17 ноктасыннан көнчыгыш-көньяк-көнчыгыш юнәлеше буенча чик 16:14:990147 кадастр кварталы чиге буйлап 18 ноктасына кадәр уза |
| 18 | 20 | 18 ноктасыннан көньяк-көньяк-көнбатышка таба чик Р-241 республика автомобиль юлы һәм 16:14:990147, 16:14:990159 кадастр кварталлары чиге буйлап 20 ноктасына кадәр уза |
| 20 | 22 | 20 ноктасыннан көнбатышка-көньяк-көнбатышка таба чик Р-241 республика автомобиль юлы һәм 16:14:990159 |

| | | |
|---|---|---|
| | | кадастр кварталы территориясе буйлап 22 ноктасына кадәр уза |
| 22 | 27 | 22 ноктасыннан көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба чик Р-241 республика автомобиль юлы һәм 16:14:990159, 16:14:990158 кадастр кварталлары чиге буйлап 27 ноктасына кадәр уза |
| 1 | 2 | 3 |
| 27 | 28 | 27 ноктасыннан көнбатышка таба чик Р-241 республика автомобиль юлы һәм 16:14:990158 кадастр кварталы чиге буйлап 28 ноктасына кадәр уза |
| 28 | 29 | 28 ноктасыннан төньякка таба чик Кадремов урамы һәм 16:14:990158, 16:14:990157 кадастр кварталлары чиге буйлап 29 ноктасына кадәр уза |
| 29 | 30 | 29 ноктасыннан көнбатышка-төньяк-көнбатышка таба чик Луговая урамы һәм 16:14:990156 кадастр кварталы чиге буйлап 30 ноктасына кадәр уза |
| 30 | 32 | 30 ноктасыннан төньяк-төньяк-көнчыгышка таба чик Казанкин урамы һәм 16:14:990156 кадастр кварталы территориясе буйлап 32 ноктасына кадәр уза |
| 32 | 33 | 32 ноктасыннан көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба чик Бебель урамы һәм 16:14:990156 кадастр кварталы территориясе буйлап 33 ноктасына кадәр уза |
| 33 | 35 | 33 ноктасыннан төньяк-төньяк-көнчыгышка таба чик Колхоз урамы һәм 16:14:990156, 16:14:990150 кадастр кварталлары чиге буйлап 35 ноктасына кадәр уза |
| 35 | 36 | 35 ноктасыннан төньяк-көнчыгышка таба чик Колхоз урамы һәм 16:14:990150 кадастр кварталы чиге буйлап 36 ноктасына кадәр уза |
| 36 | 1 | 36 ноктасыннан төньяк-төньяк-көнчыгышка таба чик Колхоз урамы һәм 16:14:990140, 16:14:990143 кадастр кварталлары чиге буйлап 1 ноктасына кадәр уза |

# 4 бүлек
# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

Объект чикләренең күзәтү схемасы





Масштабы 1: 5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр

▭ - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

1 нче бит




Масштабы 1: 3 200


Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

## Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

2 нче бит




Масштабы 1: 3 200


Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

## Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

3 нче бит




Масштабы 1: 3 200


Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

4 нче бит




Масштабы 1: 3 200


Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге территориясе чикләренең урнашу схемасы

5 нче бит





Масштабы 1: 3 200

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге
территориясе чикләренең урнашу схемасы
6 нчы бит




Масштабы 1: 3 200

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

1 - Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләренең характерлы ноктасы

- Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2026 елның
25 маендагы 295-П
номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеген саклау предметы**

1. Шәһәр барлыкка китерүче тарихи кыйммәткә ия объектлар:

| № | Объектның исеме | Урнашу урыны | Фотография |
|---|---|---|---|
| *Вахитов ур.* | | | |
| Г.1 | Торак йорт | Вахитов ур., 53 |  |
| Г.2 | Бина | Вахитов ур., 74 |   |
| Г.3 | Торак йорт | Вахитов ур., 97 |  |
| *Ефремов ур.* | | | |
| Г.4 | Торак йорт | Ефремов ур., 58 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Жорес ур.* | | | |
| Г.5 | Торак йорт | Жорес ур., 49/35 |  |
| Г.6 | Торак йорт | Жорес ур., 55 |  |
| Г.7 | Торак йорт | Жорес ур., 61/43 |  |
| Г.8 | Торак йорт | Жорес ур., 70/33 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Космовский ур.* | | | |
| Г.9 | Шәһәр электр станциясе бинасы | Космовский ур., 33/41 |  |
| *Кызыл Армия ур.* | | | |
| Г.10 | Торак йорт | Кызыл Армия ур., 63 |  |
| Г.11 | Торак йорт | Кызыл Армия ур., 65 |  |
| Г.12 | Торак йорт | Кызыл Армия ур., 72/93 |  |
| *Ленин ур.* | | | |
| Г.13 | Торак йорт | Ленин ур., 40 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Г.14 | Торак йорт | Ленин ур., 56 |  |
| *К. Либкнехт ур.* | | | |
| Г.15 | Бина | К. Либкнехт ур., 49 |  |
| Г.16 | Торак йорт | К. Либкнехт ур., 58 |  |
| Г.17 | Административ бина | К. Либкнехт ур., 60 |  |
| Г.18 | Торак йорт | К. Либкнехт ур., 62 |  |
| Г.19 | Торак йорт | К. Либкнехт ур., 66 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Роза Люксембург ур.* | | | |
| Г.20 | Административ бина | Роза Люксембург ур., 59Б |  |
| Г.21 | Торак йорт | Роза Люксембург ур., 59/57 |  |
| Г.22 | Торак йорт | Роза Люксембург ур., 73 |  |
| Г.23 | Торак йорт | Роза Люксембург ур., 77/80 |  |
| Г.24 | Торак йорт | Роза Люксембург ур., 79 |  |
| *К. Маркс ур.* | | | |
| Г.25 | Торак йорт | К. Маркс урамы, 19 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Г.26 | Бина | К. Маркс урамы, 84 |  |
| | | *Төньяк Коммуна ур.* | |
| Г.27 | Торак йорт | Төньяк Коммуна ур., 11 |  |
| Г.28 | Бина | Төньяк Коммуна ур., 51 |  |
| | | *Энгельс ур.* | |
| Г.29 | Торак йорт | Энгельс ур., 5 |  |
| Г.30 | Торак йорт | Энгельс ур., 16 |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Г.31 | Торак йорт | Энгельс ур., 27 |  |
| Г.32 | Торак йорт | Энгельс ур., 43 |  |

Шәһәрне формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объектлар, аларның төп күләме, биеклеге һәм габаритлары, тарихи фасадларны хәл итүнең стилистик үзенчәлекләре, шәһәрнең иҗтимагый киңлекләрен (урамга караган һәм урамнан күренеп торган торец өлешләре), түбә конфигурацияләре, фасадларны бизәүнең тарихи материаллары һәм түбә материалы сакланырга тиеш.

Шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия объектларны, шул исәптән алга таба торгызып та, сүтү тыела. Фасадларны декоратив бизәүнең югалган тарихи детальләре ремонт һәм реконструкция вакытында торгызылырга тиеш.

2. Элементларын да кертеп, территорияне планлаштыру структурасы.

Сакланырга тиеш:

– Буа шәһәренең көньяк (Сембергә юл) һәм төньяк-көнбатыш Стороремов урамы (Казан тракты) һәм төньяк-көнчыгыш Космовский урамы (Тәтеш шәһ.) якларыннан керү юллары булган планлаштыру структурасы;

– Жорес урамы буйлап төньяк-көнчыгыш сызыклары буенча Р.Карла су басмасы өсте террасасына параллель рәвештә һәм төньяк-көнбатышка таба планлаштыру структурасы: Бебель һәм Вахитов урамнары (Малремов урамына кадәр), Кече Яр буе урамы, рельеф буенча – Р. Люксембург урамы;

– 1804 елгы даими генплан буенча Буа шәһәренең планлаштыру структурасы:

– Ленин урамыннан төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба көньяктарак трассировкаланган *буй урамнар*:

Кече Яр буе урамы;

Жорес урамы (Сенная);

Космовский урамы (элеккеге Поповая);

Р.Люксембург урамы (элеккеге Новая);

Ефремов урамы (элеккеге Казан);

Колхоз урамы (элекке Югары Нагорная).

– *аркылы урамнар* (Сәүдә мәйданыннан сулда – татар бистәсе, уңда – рус өлеше):

Бебель урамы (элеккеге Иске Базар);

Вахитов урамы (Иске Почта урамы);

К.Либкнехт урамы (элеккеге Түбән Татар-Түбән Печән);

К. Маркс урамы (элеккеге Югары Татар-Юеш);

Энгельс урамы (элеккеге Троицкая);

Ленин урамы (элеккеге Нагорная).

– *1850 ел планы буенча аркылы урамнар:*

Кызыл Армия урамы (элеккеге Кирпеч);

Төньяк Коммуна урамы (элеккеге Зират);

Напольная урамы;

– Ленин урамыннан төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба төньякка *буй урамнар :*

Кече Яр буе урамы;

Жорес урамы (элеккеге Печән);

Космовский урамы (элеккеге Попов);

Р.Люксембург урамы (элеккеге Новая);

Ефремов урамы (элеккеге Казан);

Колхоз урамы (элекке Югары Нагорная).

– Вахитов, Жорес, К.Либкнехт, Карл Маркс, Р.Люксембург урамнары белән чикләнгән Покров ярминкәсе базар мәйданы урыны.

3. Күләм-киңлек структурасы.

Сакланырга тиеш:

– Карлы елгасы буйлап буй-буй юнәлеш алган урамнарның (Ефремов, Космовский, Жорес урамнары) һәм елгага таба аркылы юнәлешләр белән чыга торган урамнарның (Кызыл Армия, Ленин, Энгельс, К. Маркс, К. Либкнехт, Вахитов урамнары) даими челтәре белән шәһәр үзәгенең күләм-киңлек структурасы;

– Троица соборының урнашу урыны һәм аның әйләнә-тирәдәге төзелештә өстенлек итүче роле;

– мәчетләрнең вертикаль доминантларының өстенлек итүче роле;

– вак масштаблы гади төзелешнең урам габаритлары белән традицион нисбәте;

– шәһәр үзәген формалаштыручы ике катлы тарихи төзелеш характеристикалары (корылманың биеклеге, күләм-киңлек композициясе, биналарның физик үлчәмнәре, биналарның стилистикасы, урам фронтын оештыру характеры һәм корылманың җир кишәрлегендә урнашуы);

– биналарны урам буйлап кую ритмы;

– морфотиплы гади кварталлар төзелешенең периметраль характеры: капка һәм палисадалы комплекста кирпечтән һәм агачтан дисперслы утар төзелеше; аерым торучы биналар белән иҗтимагый кирпеч төзелеше; мезонинлы һәм мезонинсыз, түрбакчасыз бер катлы торак йортлар; XIX – XX гасырларның иҗтимагый агач биналары; кызыл сызык буенча фронтоннар белән түрбакчаларсыз (XIX-XX гасырлар); түрбакчалардан тыш төзелеш сызыгы буйлап вальма түбәле торак йортлар (XX гасыр); XX-XXI гасырлар совет чоры төзелеше.

4. Төзелешнең композициясе һәм силуэты (вертикаль һәм горизонталь доминантлар һәм акцентлар нисбәте).

Сакланырга тиеш:

*Төзелешнең композициясе һәм силуэты* - вертикаль һәм горизонталь доминантлар һәм акцентлар нисбәте:

– Карлы елгасы яры ягыннан шәһәрнең тарихи өлеше панорамасы;

– «картиналарга», шәһәр панорамасына күзәтүнең төп төр нокталары һәм секторлары;

– тарихи доминантларның бербөтен киңлек-композицион нисбәтенең фрагментлары: Троица соборы (Космовский ур., 42), Мәчет (Ефремов ур., 81/108);

– җирле акцентлар: земство идарәсе бинасы (Ленин ур., 52), даруханә (Жорес ур., 65).

5. Төрле шәһәр киңлекләре (ирекле, төзелгән, яшелләндерелгән) арасындагы нисбәт.

Сакланырга тиеш:

Тарихи җирлек чикләрендәге территория – 177,2 га (100%), шулардан:

– төзелгән территория, торак кварталлар чикләрендә – 155,4 га (88%);

– урамнарны, юлларны, мәйданнарны кертеп, гомуми файдаланудагы төзелешсез территорияләр – 7,0 га (4%);

– табигый-мәдәни ландшафтның төзелешсез территорияләре, төзелмәгән территорияләрне һәм Карлы елгасы кушылдыгын да кертеп, – 14,8 га (8%), шулардан 3,2 га (2%) урман үсә.


6. Композицион-төр бәйләнешләре (панорамалар), табигый һәм кеше тудырган әйләнә-тирәлекнең нисбәте.

Сакланырга тиеш:


– Буа шәһәре тарихи җирлегенең пейзаж күренешләре – урман-дала ландшафтының ачык киңлегендә чокырлар, балкалар, күл чокырлары, Иделнең икенче басма өсте террасасының текә битләре булган XIII-XIV гасырларның архитектура һәйкәлләре;

– тарихи рәвештә барлыкка килгән визуаль бәйләнешләр;

– панорама һәм төр ачышлары.


| | |
|---|---|
|  | А<br>Үзәк паркка күренеш |
|  | Б<br>Буа драма театрына күренеш |

| | |
|---|---|
|  | В<br>икенче җәмигъ мәчетенә күренеш |
|  | Г<br>һәлак булган интернационалист-сугышчылар һәйкәленә күренеш |
|  | Д<br>мемориаль комплекска күренеш |

| | |
|---|---|
|  | Е<br>көньяк-көнбатыш юнәлешендә үзәк мәйданга күренеш |
|  | Ж<br>төньяк-көнчыгыш юнәлештә үзәк мәйданга күренеш |
|  | З<br>Троица соборына күренеш |

| | |
|---|---|
|  | И<br>Адав-Толымбай авылының көньяк-көнчыгыш ягыннан шәһәргә кергәндә панорама |
|  | К<br>Р241 трассасы буенча Карлы авылы ягыннан шәһәргә кергәндә панорама |


# Традицион панорама һәм төрле ачылышлар нокталары схемасы



Традицион панорама һәм төрле ачылышлар нокталарының координаталар таблицасы

| Нокта исеме | Нокталарның тасвирламасы | WGS-84 | | МСК-16 | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | N | E | X | Y |
| А | Үзәк паркка күренеш | 48°17'40".54 | 54°57'47".23 | 1252785.08 | 384042.43 |
| Б | Буа драма театрына күренеш | 48°17'25".16 | 54°57'52".46 | 1252513.07 | 384207.18 |
| В | икенче җәмигъ мәчетенә күренеш | 48°17'09".72 | 54°58'03".50 | 1252242.08 | 384551.39 |
| Г | һәлак булган интернационалист-сугышчылар һәйкәленә күренеш | 48°17'16".69 | 54°57'52".35 | 1252362.41 | 384205.41 |
| Д | мемориаль комплекска күренеш | 48°17'17".92 | 54°57'54".03 | 1252384.85 | 384257.24 |
| Е | көньяк-көнбатыш юнәлештә үзәк мәйданга күренеш | 48°17'20".33 | 54°57'55".79 | 1252428.24 | 384311.03 |
| Ж | төньяк-көнчыгыш юнәлештә үзәк мәйданга күренеш | 48°17'18".32 | 54°57'52".55 | 1252391.44 | 384211.41 |
| З | Троица соборына күренеш | 48°17'35".84 | 54°57'54".03 | 1252703.67 | 384253.76 |
| И | Адав-Толымбай авылының көньяк-көнчыгыш ягыннан шәһәргә кергәндә күренеш | 48°18'09".92 | 54°57'36".62 | 1253304.33 | 383708.92 |
| К | Р241 трассасы буенча Карлы авылы ягыннан шәһәргә кергәндә күренеш | 48°16'53".73 | 54°57'27".46 | 1251945.67 | 383440.09 |

# Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлегенең тарихи-мәдәни терәк планы





**Список исторических ценных градоформирующих**

| № п/п | Наименование | Местоположение |
|---|---|---|
| Г.1 | Жилой дом | ул. Вахитова, 53 |
| Г.2 | Здание | ул. Вахитова, 74 |
| Г.3 | Жилой дом | ул. Вахитова, 97 |
| Г.4 | Жилой дом | ул. Ефремова, 58 |
| Г.5 | Жилой дом | ул. Жореса, 49/35 |
| Г.6 | Жилой дом | ул. Жореса, 55 |
| Г.7 | Жилой дом | ул. Жореса, 61/43 |
| Г.8 | Жилой дом | ул. Жореса, 70/33 |
| Г.9 | Здание городской электростанции | ул. Космовского, 33/41 |
| Г.10 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 63 |
| Г.11 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 65 |
| Г.12 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 72/93 |
| Г.13 | Жилой дом | ул. Ленина, 40 |
| Г.14 | Жилой дом | ул. Ленина, 56 |
| Г.15 | Здание | ул. К. Либкнехта,49 |
| Г.16 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 58 |
| Г.17 | Административное здание | ул. К. Либкнехта, 60 |
| Г.18 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 62 |
| Г.19 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 66 |
| Г.20 | Административное здание | ул. Розы Люксембург, 59Б |
| Г.21 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 59/57 |
| Г.22 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 73 |
| Г.23 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 77/80 |
| Г.24 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 79 |
| Г.25 | Жилой дом | ул. К. Маркса, 19 |
| Г.26 | Здание | ул. К. Маркса, 84 |
| Г.27 | Жилой дом | ул. Северной Коммуны, 11 |
| Г.28 | Здание | ул. Северной Коммуны, 51 |
| Г.29 | Жилой дом | ул. Энгельса, 5 |
| Г.30 | Жилой дом | ул. Энгельса, 16 |
| Г.31 | Жилой дом | ул. Энгельса, 27 |
| Г.32 | Жилой дом | ул. Энгельса, 43 |

**Список ОКН, включенных в единый реестр ОКН народов Российской Федерации**

| № по пп | Наименование объектов культурного наследия | Датировка | Местонахождение ОКН, в соответствии с данными органов технической инвентаризации |
|---|---|---|---|
| *Регионального значения* | | | |
| 1 | Мечеть | нач. XX в. (рекон. 1988 г.) | ул. Ефремова, 81 / ул. Энгельса, 108 |
| 2 | Аптека | 1902 г. | ул. Жореса, 65 / ул. Красноармейская, 41 |
| 3 | Дом Бурундуковского | нач. XX в. | ул. Розы Люксембург, 51 |
| 4 | Училище реальное | 1908 - 1910 гг. | ул. Северной Коммуны, 41 |
| 5 | Здание земской управы, где размещалась 1-я уездная ячейка РСДРП(б) | 1888 - 1904 гг., 1918 - 1920 гг. | ул. Ленина, 52 / ул. Космовского, 29 |
| 6 | Троицкий собор | 1719 г., 1813 г., 1828 г | ул. Космовского, 42/45 |
| 7 | Жилой дом | конец XIX в. | ул. Карла Либкнехта, 42/29 |
| 8 | Жилой дом помещика Авксентьева | XIX в. | ул. Розы Люксембург, 39 |
| 9 | Здание присутственных мест (ныне Буинский краеведческий музей) | 2-я половина XIX в. | ул. К. Маркса, 70 |
| *Выявленные объекты культурного наследия (Приказ МК РТ от 01.01.2002 г.)* | | | |
| В.1 | Комплекс зданий медресе | конец XIX в. | ул. Ефремова, 57 (ранее Интернациональная ул., 67) |
| В.2 | Комплекс зданий медресе | конец XIX в. | ул. Карла Либкнехта, 77-79 |

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеген саклау предметын график тасвирлау схемасы




**Список исторических ценных градоформирующих**

| № п/п | Наименование | Местоположение |
|---|---|---|
| Г.1 | Жилой дом | ул. Вахитова, 53 |
| Г.2 | Здание | ул. Вахитова, 74 |
| Г.3 | Жилой дом | ул. Вахитова, 97 |
| Г.4 | Жилой дом | ул. Ефремова, 58 |
| Г.5 | Жилой дом | ул. Жореса, 49/35 |
| Г.6 | Жилой дом | ул. Жореса, 55 |
| Г.7 | Жилой дом | ул. Жореса, 61/43 |
| Г.8 | Жилой дом | ул. Жореса, 70/33 |
| Г.9 | Здание городской электростанции | ул. Космовского, 33/41 |
| Г.10 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 63 |
| Г.11 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 65 |
| Г.12 | Жилой дом | ул. Красноармейская, 72/93 |
| Г.13 | Жилой дом | ул. Ленина, 40 |
| Г.14 | Жилой дом | ул. Ленина, 56 |
| Г.15 | Здание | ул. К. Либкнехта,49 |
| Г.16 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 58 |
| Г.17 | Административное здание | ул. К. Либкнехта, 60 |
| Г.18 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 62 |
| Г.19 | Жилой дом | ул. К. Либкнехта, 66 |
| Г.20 | Административное здание | ул. Розы Люксембург, 59Б |
| Г.21 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 59/57 |
| Г.22 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 73 |
| Г.23 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 77/80 |
| Г.24 | Жилой дом | ул. Розы Люксембург, 79 |
| Г.25 | Жилой дом | ул. К. Маркса, 19 |
| Г.26 | Здание | ул. К. Маркса, 84 |
| Г.27 | Жилой дом | ул. Северной Коммуны, 11 |
| Г.28 | Здание | ул. Северной Коммуны, 51 |
| Г.29 | Жилой дом | ул. Энгельса, 5 |
| Г.30 | Жилой дом | ул. Энгельса, 16 |
| Г.31 | Жилой дом | ул. Энгельса, 27 |
| Г.32 | Жилой дом | ул. Энгельса, 43 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2026 елның
25 маендагы 295-П
номерлы боерыгына
3 нче кушымта

**Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендәге шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр**

**ИП-С (1)** – XVIII гасырда Карлы елгасы буендагы авыл чикләрендәге тарихи Буа җирлегенең индивидуаль торак төзелешен, шулай ук иҗтимагый-эшлекле зоналарның кишәрлекләрен саклап калуны күздә тоткан зонасы.

**ИП-С (2)** – 1895 һәм 1960 елгы генераль планнарны һәм даими планлаштыру элементларын гамәлгә ашырганда формалаштырылган, шулай ук мәдәни мирас объектлары өчен фон төзелеш ролен үтәүче тарихи үзәк төзелеше масштабын һәм стилистикасын саклап калу максатларында урнаштырылган Буа тарихи җирлегенең барлыкка килгән тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать пространствосын саклап калуны һәм үстерүне күздә тота торган, капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны күздә тота торган зонасы.

**ИП-Л** – Карлы елгасының уң яр буе рельефының характерын исәпкә алып, Карлы елгасы яр буе, су объектлары һәм яшел утыртмалар буендагы тарихи Буа торак пункты зонасы.

**ИП-П** – Буа тарихи җирлегенең җитештерү, коммуналь һәм агротехник объектлар, яшелләндерү зоналары территорияләрендә билгеләнә торган зонасы.

## I. ИП-С (1) индексы булган зонада шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр

**Күздә тотыла:**

тарихи планлаштыру структурасы элементларын, урамнар төзүнең тарихи линияләрен саклау;

төзелеш фронтын, шул исәптән ачык һәм ябык пространстволар нисбәтен, төзелеш линиясе дискретлыгын саклау;

шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объектларны саклау, аларны консервацияләү һәм югалган элементларны, фасадларны торгызуны күздә тоткан капиталь ремонт;

тарихи төзелеш комплексының югалган элементларын тарихи мохитне регенерацияләүгә юнәлдерелгән махсус чаралар куллану кысаларында элеккеге биеклек һәм план габаритларыннан артмыйча торгызу (яңарту).

**Рөхсәт ителә**:

капиталь төзелеш һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, шул исәптән законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган бер төр архитектура чишелешләре нигезендә дә, шәһәр төзелеше регламентлары таләпләре нигезендә,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы карары) белән төзелгән Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия карарлары нигезендә капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү;

«Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башлар алдыннан археологик мирас объектларының яисә археологик мирас объекты билгеләренә ия объектларның булу-булмавын билгеләү максатында археологик кыр эшләрен үткәрү;

гамәлдәге законнар нигезендә мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкару;

мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт органы бәяләмәсе нигезендә архив һәм тарихи-мәдәни тикшеренүләр белән расланган тарихи-мәдәни кыйммәте булмаганда диссонияле һәм гармониясез объектларны сүтү;

мәдәни мирас объектларын визуаль кабул итүгә һәм барлыкка килгән архитектура даирәсенә, шул исәптән шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия объектларга тискәре йогынтыны бетереп, яңа төзелеш объектларының архитектура стилистик характеристикаларын әйләнә-тирә тарихи-шәһәр төзелеше мохитенә яраклаштыру;

тарихи җирлекне саклау предметы һәм тарихи-шәһәр төзелеше мохите элементларын (шул исәптән саклау предметының, тарихи-шәһәр төзелеше һәм/яки табигать мохитенең өлешчә яисә тулысынча югалган элементларын һәм/яисә характеристикаларын торгызу, яңадан торгызу, тулыландыру) тарихи мохитне регенерацияләүгә юнәлдерелгән махсус чаралар куллану кысаларында гамәлдәге элеккеге биеклек һәм план габаритларыннан арттырмыйча, тарихи-мәдәни тикшеренүләр һәм визуаль-ландшафт анализы нәтиҗәләре нигезендә билгеләнә торган параметрларда саклау эшләрен уздыру;

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

ИП-С индексы булган кишәрлекләр чикләрендә капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителә торган иң чик биеклек тамгасы – түбә тимераягына кадәр 9 м;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән төзелгән Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия тарафыннан гамәлдәге биеклек һәм план габаритларын үзгәртеп, капиталь төзелеш һәм реконструкция объектларының архитектура чишелешләрен карау һәм килештерү.

**Тыела**:

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларына зыян китерү, җимерү, юкка чыгару яисә характеристикаларын бозу куркынычын тудыра торган җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм башкару;

тарихи кыйммәткә ия шәһәр формалаштыручы объектлар өчен: фасадларны сүтү, декоратив һәм архитектур-стилистик характеристикаларны үзгәртү, фасадларны бизәүнең тарихи материалларын үзгәртү, тарихи типологияне һәм түбә авышлыгы почмагын үзгәртү, шул исәптән сынган түбәгә, ян фасадларга янкорма (озынлыгы төзелешнең төп линиясе буенча төп фасад озынлыгының өчтән береннән дә артмаган верандалар һәм террасалардан тыш), бинаның биеклеген һәм габаритларын үзгәртү (йортның арткы фасадына янкормадан тыш), фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияли торган);

яңа төзелеш һәм реконструкция вакытында: биләмәләрне төзүнең тарихи барлыкка килгән композицион-киңлек тибын, түбәләрне ябу характерын үзгәртү; фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияләүче); төзелешнең тарихи линиясе буйлап урнашкан яки урнаштырыла торган биналар һәм корылмалар янында яссы түбәләр формалаштыру;

капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, рөхсәт ителә торган биеклек билгесеннән (тимераякка кадәр 9 м) арттырып;

мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган коймалар һәм металл коймалар урнаштыру, урам фронты буенча койма өчен профнастил, металлопластик, пластик, бетон плитәләр куллану;

мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган реклама, вакытлы корылмалар, киосклар урнаштыру;

туфракны, грунт суларын һәм җир өстендәге агынтыларны пычратуга бәйле хуҗалык эшчәнлеге;

җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру һәм күмү, складлар һәм агулы химикат күмү урыннары төзү; үләт базлары урнаштыру;

чүплекләрне махсус билгеләнгән урыннардан читтә урнаштыру һәм чүп-чар өчен җиһазландырылмаган урыннар оештыру.

## II. ИП-С (2) индексы белән даими планлаштыру зонасында шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр

**Күздә тотыла:**

тарихи планлаштыру структурасы элементларын, шул исәптән биләмәләрнең тарихи чикләрен, урамнар төзүнең тарихи линияләрен саклау;

төзелеш фронтын, шул исәптән ачык һәм ябык пространстволар нисбәтен, төзелеш линиясе дискретлыгын саклау;

шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объектларны саклау, аларны консервацияләү һәм югалган элементларны торгызуны күздә тоткан капиталь ремонт;

**Рөхсәт ителә**:

капиталь төзелеш һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, шул исәптән законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган бер төр архитектура чишелешләре нигезендә дә, шәһәр төзелеше регламентлары таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән төзелгән Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия карарлары нигезендә капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү;

мәдәни мирас объектларын визуаль кабул итүгә һәм барлыкка килгән архитектура даирәсенә, шул исәптән шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия объектларга тискәре йогынтыны бетереп, яңа төзелеш объектларының архитектура стилистик характеристикаларын әйләнә-тирә тарихи-шәһәр төзелеше мохитенә яраклаштыру;

тарихи җирлекне саклау предметы элементларын һәм тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклау буенча эшләр башкару (саклау предметының, тарихи-шәһәр төзелеше һәм/яки табигать мохитенең өлешчә яисә тулысынча югалган элементларын һәм/яисә характеристикаларын торгызу, яңадан торгызу, тулыландыру);

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

ИП-С индексы булган кишәрлекләр чикләрендә капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителә торган иң чик биеклек тамгасы – түбә тимераягына кадәр 11 м;

Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башлар алдыннан археологик мирас объектларының яки археологик мирас объекты билгеләренә ия объектларның булу-булмавын билгеләү максатыннан 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә археологик кыр эшләрен башкару.

**Тыела:**

тарихи кыйммәткә ия шәһәр формалаштыручы объектлар өчен: фасадларны сүтү, декоратив һәм архитектур-стилистик характеристикаларны үзгәртү, фасадларны бизәүнең тарихи материалларын үзгәртү, тарихи типологияне һәм түбә авышлыгы почмагын үзгәртү, шул исәптән сынган түбәгә, ян фасадларга янкорма (озынлыгы төзелешнең төп линиясе буенча төп фасад озынлыгының өчтән береннән дә артмаган верандалар һәм террасалардан тыш), бинаның биеклеген һәм габаритларын үзгәртү (йортның арткы фасадына янкормадан тыш), фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияли торган);

капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, рөхсәт ителә торган биеклек билгесеннән (тимераякка кадәр 11 м) арттырып;

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларына зыян китерү, җимерү, юкка чыгару яисә характеристикаларын бозу куркынычын тудыра торган җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм башкару;

яңа төзелеш һәм реконструкция вакытында: биләмәләрне төзүнең тарихи барлыкка килгән композицион-киңлек тибын, түбәләрне ябу характерын үзгәртү; фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияләүче); төзелешнең тарихи линиясе буйлап урнашкан яки урнаштырыла торган биналар һәм корылмалар янында яссы түбәләр формалаштыру;

мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган коймалар һәм металл коймалар урнаштыру, урам фронты буенча койма өчен профнастил, металлопластик, пластик, бетон плитәләр куллану;

мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган реклама, вакытлы корылмалар, киосклар урнаштыру;

туфракны, грунт суларын һәм җир өстендәге агынтыларны пычратуга бәйле хуҗалык эшчәнлеге;

җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру һәм күмү, складлар һәм агулы химикат күмү урыннары төзү; үләт базлары урнаштыру;

чүплекләрне махсус билгеләнгән урыннардан читтә урнаштыру һәм чүп-чар өчен җиһазландырылмаган урыннар оештыру.

## III. ИП-Л индексы булган зоналарда шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр

**Күздә тотыла:**

табигый ландшафтны, шул исәптән елгаларның яр буйларын саклау;

кыйммәтле төр ачылышларын визуаль кабул итүне тәэмин итү максатларында ачык һәм ябык пространстволарның барлыкка килгән нисбәтен саклап калу;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә тарихи җирлекнең саклау предметы элементларының сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле таләпләрне үтәү;

тарихи җирлекне саклау предметы элементын саклауны һәм торгызуны (регенерацияләүне) тәэмин итү өчен кирәкле әйләнә-тирә мохит сыйфатын саклау.

**Рөхсәт ителә:**

табигый ландшафт элементларын, рельеф үзенчәлекләрен, гидрографияне саклап калуга юнәлдерелгән чараларны үткәрү;

тарихи җирлекне саклау предметы элементын визуаль кабул итүне бозмый торган элементлар кулланып, төзекләндерү һәм яшелләндерү.

**Тыела:**

Карлы елгасының яр сызыгы конфигурациясен үзгәртү;

капиталь төзелеш объектларын урнаштыру;

территориянең ландшафт характеристикаларын бозу, шул исәптән табигый рельеф характеристикаларын үзгәртү;

табигый һәм табигый-антропоген объектларга һәм комплексларга, су объектларының һәм гидрографик челтәр элементларының санитария торышына һәм гидрологик режимына зыян китерә торган, экологик вәзгыятьнең начараюына, территориянең табигый кыйммәтен, эстетик һәм рекреацион сыйфатларын киметүгә яисә юкка чыгаруга китерә торган эшчәнлек;

туфракны, грунт суларын һәм җир өстендәге агынтыларны пычратуга бәйле хуҗалык эшчәнлеге;

учаклар ягу, үлән үсемлекләрен яндыру (үлән яндыруларны үткәрү);

агач һәм куакларны үз белдегең белән утырту (кисү);

транспорт чаралары тукталышлары урнаштыру;

мәдәни мирас объектларын, ачыкланган мәдәни мирас объектларын һәм тарихи-шәһәр төзелеше мохите объектларын визуаль кабул итүне боза торган мәгълүмати конструкцияләр (шул исәптән аерым торганнарын), элмә такталар, күрсәткечләр (мәдәни мирас объектларын популярлаштыру эшчәнлегенә бәйле булганнарыннан тыш) урнаштыру;

җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру һәм күмү, агулы химикат складларын һәм аларны күмү урыннарын төзү; үләт базлары урнаштыру.

## IV. ИП-П индексы булган зонада шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр

**Күздә тотыла:**

гамәлдәге Классификатор нигезендә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төрләрен төшереп калдыру: Файдалы казылмалар табу һәм чыгару (6.1); Авыр сәнәгать (6.2); Автомобиль төзелеше сәнәгате (6.2.1); Җиңел сәнәгать (6.3); Нефть химиясе сәнәгате (6.5); Төзелеш сәнәгате (6.6); Атом энергетикасы (6.7.1); Целлюлоза-кәгазь сәнәгате (6.11).

**Рөхсәт ителә:**

тарихи планлаштыру структурасы элементларын, шул исәптән биләмәләрнең тарихи чикләрен, урамнар төзүнең тарихи линияләрен саклау;

төзелеш фронтын, шул исәптән ачык һәм ябык пространстволар нисбәтен, төзелеш линиясе дискретлыгын саклау;

шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия объектларны саклау, аларны консервацияләү һәм югалган элементларны торгызуны күздә тоткан капиталь ремонт;

капиталь төзелеш һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, шул исәптән законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган бер төр архитектура чишелешләре нигезендә дә, шәһәр төзелеше регламентлары таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән төзелгән Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия карарлары нигезендә капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү;

мәдәни мирас объектларын визуаль кабул итүгә һәм барлыкка килгән архитектура даирәсенә, шул исәптән шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия объектларга тискәре йогынтыны бетереп, яңа төзелеш объектларының архитектура стилистик характеристикаларын әйләнә-тирә тарихи-шәһәр төзелеше мохитенә яраклаштыру;

тарихи җирлекне саклау предметы элементларын һәм тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклау буенча эшләр башкару (саклау предметының, тарихи-шәһәр төзелеше һәм/яки табигать мохитенең өлешчә яисә тулысынча югалган элементларын һәм/яисә характеристикаларын торгызу, яңадан торгызу, тулыландыру);

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

ИП-П индексы булган кишәрлекләр чикләрендә капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителә торган иң чик биеклек тамгасы – түбә тимераягына кадәр 14 м;

Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башлар алдыннан археологик мирас объектларының яки археологик мирас объекты билгеләренә ия объектларның булу-булмавын билгеләү максатыннан 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә археологик кыр эшләрен башкару.

**Тыела:**

тарихи кыйммәткә ия шәһәр формалаштыручы объектлар өчен: фасадларны сүтү, декоратив һәм архитектур-стилистик характеристикаларны үзгәртү, фасадларны бизәүнең тарихи материалларын үзгәртү, тарихи типологияне һәм түбә авышлыгы почмагын үзгәртү, шул исәптән сынган түбәгә, ян фасадларга янкорма (озынлыгы төзелешнең төп линиясе буенча төп фасад озынлыгының өчтән береннән дә артмаган верандалар һәм террасалардан тыш), бинаның биеклеген һәм габаритларын үзгәртү (йортның арткы фасадына янкормадан тыш), фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияли торган);

капиталь төзелеш объектларын төзү, капиталь ремонтлау, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителә торган биеклек билгесеннән (тимераякка кадәр 14 м) арттырып реконструкцияләү;

тарихи җирлекнең саклау предметы элементларына зыян китерү, җимерү, юкка чыгару яисә характеристикаларын бозу куркынычын тудыра торган җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм башкару;

яңа төзелеш һәм реконструкция вакытында: биләмәләрне төзүнең тарихи барлыкка килгән композицион-киңлек тибын, түбәләрне ябу характерын үзгәртү; фасадларны бизәү өчен заманча материаллар куллану (пластик һәм металл сайдинг, термопанельләр, сэндвич-панельләр, керамик, фиброцемент, бетон, композит һ.б. бизәкле вентиляцияләнә торган фасадлар, шул исәптән тарихи материалларны имитацияләүче); төзелешнең тарихи линиясе буйлап урнашкан яки урнаштырыла торган биналар һәм корылмалар янында яссы түбәләр формалаштыру;

мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган коймалар һәм металл коймалар урнаштыру, урам фронты буенча койма өчен профнастил, металлопластик, пластик, бетон плитәләр куллану;


мәдәни мирас объектларын һәм тарихи җирлекне саклау предметы элементларын визуаль кабул итүне боза торган реклама, вакытлы корылмалар, киосклар урнаштыру;

туфракны, грунт суларын һәм җир өстендәге агынтыларны пычратуга бәйле хуҗалык эшчәнлеге;

җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру һәм күмү, складлар һәм агулы химикат күмү урыннары төзү; үләт базлары урнаштыру;

чүплекләрне махсус билгеләнгән урыннардан читтә урнаштыру һәм чүп-чар өчен җиһазландырылмаган урыннар оештыру.

# Буа шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендәге территориаль зоналар картасы (схемасы)





Масштабы 1:5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

- ИП-С (1)
- ИП-С (2)
- ИП-П
- ИП-Л
- шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объект

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендә ИП-С (1) индексы булган территориаль зона картасы (схемасы)





Масштабы 1:5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

- ИП-С (1)

- шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объект

## Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендә ИП-С (2) индексы булган территориаль зона картасы (схемасы)





Масштабы 1:5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

- ИП-С (2)

- шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объект

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендә индексы ИП-Л булган территориаль зона картасы (схемасы)





Масштабы 1:5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

- -ИП-Л
- - шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объект

# Буа шәһәренең региональ әһәмияттәге тарихи җирлеге чикләрендә ИП-П индексы булган территориаль зона картасы (схемасы)




Масштабы 1:5 000

Кулланыла торган шартлы тамгалар һәм билгеләр:

- ИП-П
- шәһәр формалаштыручы тарихи кыйммәткә ия объект